**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.07.2019** **№ 1109**

**Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруны (форма) билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү буенча Административ регламентны раслау турында**

“Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законны, “Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”, 2007 ел, 27 нче декабрь, 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруны (форма) билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү буенча Административ регламентны расларга.

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ веб адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Хәкимуллин Р.Ф.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта
«Расланган»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән
17.07.2019 № 1109

# Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләгән критерийларга туры килгән күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү буенча Административ регламент

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруны (форма) билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – критерийларга туры килү турында бәяләмә).

1.2. Хезмәтне алучылар булып торалар – Биектау муниципаль районы территориясендә төзелешне тормышка ашыручы, хосусый милек, субаренда хокукында яки “Торак төзелешен үстерүгә булышлык күрсәтү турында”, 2008 ел, 24 нче июль, 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.10 статьясы, 2 пункты, 15 пунктчасы түләүсез куллану хокукында җир кишәрлеген куллану һәм 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелеш катнашучыларының акчаларын, әлеге җир кишәрлегендә күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзү өчен, җитештерү өчен билгеләнгән объектлардан кала, 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясы белән күздә тотылган счетларны кулланмыйча, төзелеш өчен алынган рөхсәт нигезендә, оештыру-хокук формасына бәйле булмаган төзүчеләр – юридик затлар.

1.3. Критерияләргә туры килү турында бәяләмә бирү Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тәкъдим ителә.

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге (алга таба – орган)

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: ТР, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Кооперативная урамы, 5 нче йорт.

Бүлекнең урнашкан урыны: ТР, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Кооперативная урамы, 5 нче йорт.

Бүлекнең эш графигы, шул исәптән кабул итүгә язылу өчен: дүшәмбе – җомга, 8.00дән 17.00гә кадәр, төшке аш 12.00дән 13.00 гә кадәр, шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Керү, керүгә рөхсәт кәгазьләре һәм (яки) шәхесне ачыклаучы документ буенча.

Бүлектә гариза бирүчеләрне, аларның вәкилләрен кабул итү графигы – сишәмбе, 9.00дән 16.00гә кадәр, пәнҗешәмбе 9.00дән 16.00гә кадәр.

Бүлекнең белешмә өчен телефоны: 8 (84365) 2-30-68

1.3.2. Биектау муниципаль районының рәсми порталы адресы: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/.

Бүлекнең электрон почтасы адресы: Hamitov.Lenar@mail.ru.

1.3.3. Критерийларга туры килү турында бәяләмә алу процедурасы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) "Интернет" челтәре аша;

2) Башкарма комитетка телдән мөрәҗәгать иткән вакытта (шәхсән яки телефон буенча);

3) Башкарма комитетка язмача мөрәҗәгать иткән вакытта (шул исәптән электрон документ формасында).

1.4. Критерийларга туры килү турында бәяләмә бирү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

- "Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 214-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2005 ел, 3 нче гыйнвар, №1, 40 статья);

- "Дәүләт контролен (надзорын) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыру вакытында, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында", 2008 ел, 26 нчы декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2008 ел, 29 нчы декабрь, 52, 6249 статья);

- "Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2018 ел, 25 нче декабрь, 478-ФЗ номерлы Федераль закон;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында", 2016 ел, 19 нчы апрель, 724-р номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2016 ел, 2 нче май, №18, 2647 статья);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йортның һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсен ачыклаучы критерийлар һәм өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең саны турында, туры килгән очракта төзүчегә өлешле төзелеш катнашучыларының акчаларын җәлеп итү хокукы тәкъдим ителәә, "Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законның 15 статьясы белән күз алдында тотылган

счетларны кулланмыйча, 2019 ел, 22 нче апрель, (алга таба – РФ Хөкүмәте карары, №480) (хокуки мәгълүмат рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru);

- "Төзелеш проекты әзер булу турында гариза формасын раслау турында", 2019 ел, 24 нче май, 300/пр номерлы Россия Төзелеш министрлыгы Боерыгы;

- "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ("Татарстан Республикасы", 2004 ел, 3 нче август, №155-156);

- "Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында", 2007 ел, 27 нче декабрь, 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы («Республика Татарстан», 2007 ел, 28 нче декабрь, №259);;

- "Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында", 2004 ел, 27 нче декабрь, 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

- "Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзелеше белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында", 2019 ел, 18 нче май, 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 09.04.2019);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен төзелеш өчен граданнарның акчаларын җәлеп итүче затлардан ала торган мәгълүматлар һәм (яки) документлар исемлеге турында", 2013 ел, 11 нче октябрь 750 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары Җыелмасы, 2013 ел, 18 нче октябрь, №77);

Биектау муниципаль районы Советының 2015 ел, 21 нче сентябрь, 7 номерлы карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Биектау муниципаль районы Советының 2016 ел, 28 нче сентябрь, 86 номерлы, 2016 ел, 29 нчы ноябрь, 110 номерлы, 2017 ел, 26 нчы май, 145 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне дә истә тотып (алга таба – Устав);

Биектау муниципаль районы Советының 2017 ел, 16 нчы февраль, 122 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты" МКУ турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзелеше өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру буенча функцияләрне башкару буенча Биектау муниципаль районы

Башкарма комитетының Административ регламенты, 2018 ел, 21 нче май 1103 номерлы карар белән расланган;

- әлеге Регламент.

## II. Тәкъдим итү стандарты

| Стандартка таләпләр исемлеге | Таләпләрнең эчтәлеге | Норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Исеме | Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, әлеге объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында төзүчегә бәяләмә бирү һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру | РФ Хөкүмәтенең 480 номерлы Карары, 478 номерлы Федераль закон |
| 2.2. Җирле үзидарәнең башкарма-боерык бирү органы исеме | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты. Турыдан-туры башкаручы – Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ Бүлеге (алга таба - Бүлек). | 2019 ел, 18 нче май, 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| 2.3. Нәтиҗәнең тасвирламасы | Нәтиҗә булып, Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, әлеге объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында төзүчегә бәяләмә бирү һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру тора. | РФ Хөкүмәтенең 480 номерлы Карары, 478 номерлы Федераль закон |
| 2.4. Тәкъдим итү срогы, шул исәптән башка органнарга мөрәҗәгать итү | Проектның әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә әзерләү гариза һәм документлар кертелгәннән соң, 15 эш көне дәвамында тормышка ашырыла. | РФ Хөкүмәтенең 480 номерлы Карары, 478 номерлы |

| Стандартка таләпләр исемлеге | Таләпләрнең эчтәлеге | Норматив акт |
|---|---|---|
| кирәклеген дә күз алдында тотып, туктатып тору срогы, әгәр дә туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән күз алдында тотылган булса. | Дөрес булмаган мәгълүматлар тәкъдим иткән һәм контрольдә тотучы орган тарафыннан өстәмә документларны сорату булган очракта, объектның әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә әзерләү срогы 5 көннән дә артмаган срокка арттырыла. | Федераль закон |
| 2.5. Кирәкле документларның тулы исемлеге | 3 нче кушымта нигезендә документлар пакеты.<br>Критерийларга туры килү турында бәяләмә алу өчен гариза бланкын гариза бирүче бүлеккә шәхсән үзе мөрәҗәгать иткәндә яки электрон почта аша ала ала.<br>Җитәкченең имзасы һәм оешманың мөһере (булган очракта) белән расланган гариза һәм документлар гариза бирүче яки гариза бирүче исеменнән кәгазьдә күрсәтлегән ышанычнамә нигезендә эш итә торган зат тарафыннан ике экземплярда шәхсән үзе яки торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында төзүченең шәхси кабинеты аша, алда күрсәтелгән затларның электрон имзалары белән раслап тәкъдим итәләр. | РФ Хөкүмәтенең 480 номерлы Карары, 22.04.2019; 478 номерлы Федераль закон |
| 2.6. Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алырга мөмкин булган документлар:<br>- төзүче тарафыннан төзелгән төзелгән | 210-ФЗ номерлы Федераль закон, 27.07.2010 |

| Стандартка таләпләр исемлеге | Таләпләрнең эчтәлеге | Норматив акт |
|---|---|---|
| органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны гариза бирүче тарафыннан алу юллары, шул исәптән электрон формада, аларны тәкъдим итү тәртибе; әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы, яки оешмалар | территорияне үстерү, территорияне комплекслы үзләштерү турында, шул исәптән стандарт торак төзелеше максатларында, хокук ияләре инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү, җирле үзидарә органнары инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү;<br>- төзүченең дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы белән төзегән шартнамәләре һәм килешүләре (шул исәптән инвестицион), әгәр дә әлеге шартнамәләр яки килешүләр белән төзүченең социаль объектларны һәм (яки) инженер-техник инфраструктураны дәүләт яки муниципаль милеккә тапшыру һәм (яки) тузган һәм авария хәлендәге торакны бетерү каралган булса;<br>- бухгалтер (финанс) хисабыннан мәгълүматлар;<br>- Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан аерым затның анда булган күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтә;<br>- Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан гариза бирүче тарафыннан объект төзелеше (булдыру) алып барылган җир кишәрлегенә карата өземтә (мәгълүматлар);<br>- 3 нче кушымта нигезендә документлар пакеты;<br>- Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу юллары һәм аларны тәкъдим итү тәртибе, әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән | |

| Стандартка таләпләр исемлеге | Таләпләрнең эчтәлеге | Норматив акт |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исеме, аларны килештерү норматив-хокукый актларда каралган очракларда критерийларга туры килүе турында бәяләмә биргәндә таләп ителә. | - | - |
| 2.8. Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Әлеге регламентның 2.14 бүлегендәге таләпләргә туры килмәгән затларның мөрәҗәгать итүе.<br>2. Тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру.<br>3. Гаризада һәм гаризага беркетелгән документларда аларның эчтәлеген ачык итеп шәрехләргә мөмкинлек бирми торган төзәтүләр, хилафлыклар бар.<br>4. Тиешле булмаган органга документларны тапшыру.<br>5. Биектау муниципаль районы территориясендә булмаган объектка карата гариза тапшыру. | 214-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.9. Туктатып тору һәм баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>- Башкарма комитет тарафыннан төзүченең РФ Хөкүмәтенең 2019 ел, 22 нче апрель, 480 номерлы Карары белән билгеләнгән критерийларга туры килмәве | |

| Стандартка таләпләр исемлеге | Таләпләрнең эчтәлеге | Норматив акт |
|---|---|---|
| | ачыклану;<br>- гариза һәм тәкъдим ителгән документларда күрсәтелгән мәгълүматларның дөрес булмавын ачыклау;<br>- гариза бирүче тарафыннан әлеге регламентта тәкъдим итү өчен мәҗбүри дип күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын тәкъдим итү;<br>- гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе хокукый актлары, Татарстан Республикасы хокукый актлары, әлеге Регламент белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән гариза һәм башка документларны тәкъдим итү;<br>- үз көчен югалткан һәм гариза бирү вакытына гамәлдә булу срогы чыккан (әгәр дә документның гамәлдә булу срогы документның үзендә күрсәтелгән, яисә закон тарафыннан билгеләнгән булса, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән башка очракларда) документларны бирү;<br>- ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратылган, гариза бирүче һәм документларның закон таләпләренә туры килүен раслаучы документлар һәм мәгълматларның булмавы. | |
| 2.10. Дәүләт пошлинасын яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Түләүсез тәкъдим ителә. | - |
| 2.11. Кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтү өчен | Таләп ителми | - |

| Стандартка таләпләр исемлеге | Таләпләрнең эчтәлеге | Норматив акт |
|---|---|---|
| түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | | |
| 2.12. Гариза биргәндә һәм нәтиҗәне алганда чиратта көтеп торуның максималь вакыты | Гаризаны кәгазьдә биргәндә, чират булган очракта – 15 минуттан да артык булмаган вакыт.<br>Торак төзелеше бердәм мәгълүмати системасында гариза биргәндә һәм нәтиҗәләрне алганда чиратлар күздә тотылмый. | - |
| 2.13. Гариза бирүченең соратуын теркәү срогы | Гариза кергән көннән вакыттан бер көн эчендә | - |
| 2.14. Гариза бирүчеләр | Биектау муниципаль районы территориясендә төзелешне тормышка ашыручы, хосусый милек, субаренда хокукында яки “Торак төзелешен үстерүгә булышлык күрсәтү турында”, 2008 ел, 24 нче июль, 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.10 статьясы, 2 пункты, 15 пунктчасы түләүсез куллану хокукында җир кишәрлеген куллану һәм 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелеш катнашучыларының акчаларын, әлеге җир кишәрлегендә күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзү өчен, җитештерү өчен билгеләнгән объектлардан кала, 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясы белән күздә тотылган счетларны кулланмыйча, төзелеш өчен алынган рөхсәт нигезендә, оештыру-хокук формасына бәйле булмаган төзүчеләр - юридик затлар була ала.<br>Гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен, закон тарфыннан билгеләнгән тәртиптә | - |

| **Стандартка таләпләр исемлеге** | **Таләпләрнең эчтәлеге** | **Норматив акт** |
| --- | --- | --- |
| | гариза бирүче тарафыннан вәкаләтләнгән башка затлар тәкъдим итә ала. | |

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Критерийларга туры килү турында бәяләмә биргәндә гамәлләр тәртибе эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Туры килү турында бәяләмәне алу үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) документларны кабул итүгә язу;

3) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

4) ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү;

5) юридик зат – төзүчегә карата гомуми кулланылышта булган сайтлардан мәгълүмат (белешмәләр) алу;

6) алынган мәгълүматларны анализлау һәм тикшерү;

7) кирәк булган очракта өстәмә документларны сорату;

8) алынган документларны анализлау;

9) нәтиҗәләрне әзерләү;

10) гариза бирүчегә критерийларга туры килү турында бәяләмә бирү яисә әлеге бәяләмәне бирүдән дәлилләнгән баш тарту.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

Гариза бирүче критерийларга туры килү турында бәяләмә алу тәртибе буенча консультация алу өчен билгеле Бүлеккә шәхсән үзе, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече тарафыннан гариза бирүчегә критерийларга туры килү турында бәяләмә алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация уздырыла, кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтелә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларны тормышка ашыру гариза бирүченең теләге белән тормышка ашырыла.

3.3 Документларны кабул итү

Критерийларга туры килү турында бәяләмә алу өчен документларны кабул итү алдан язылып ((843) 652-30-68 телефон номеры аша), гариза бирүче өчен билгеләнгән вакытта Башкарма комитет бинасында бүлекнең кабул итү көннәрендә тормышка ашырыла.

3.4. Гаризаны кабул итү һәм теркәү, аны үтәүгә җибәрү

3.4.1. Гариза бирүче шәхсән үзе яки вәкаләтле зат аша, алдан билгеләнгән вакытта, кабул итү сәгатьләрендә Башкарма комитетка язмача гариза бирә. Гаризаны кабул итү һәм аларга беркетелгән документларны кабул итү Биектау районы Башкарма комитеты күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә законнарны тотуны контрольдә тоту

буенча бүлек белгече тарафыннан тормышка ашырыла (алга таба – бүлек белгече).

Бүлек белгече кергән документларның әлеге регламентның 2.5, 2.6 пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә.

Әлеге регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарта.

Төзүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтерының электрон имзасы белән расланган  гариза торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында төзүченең шәхси кабинеты аша бирелергә мөмкин.

Гаризаны кабул иткәннән соң бүлек белгече кергән документларны терки, гаризага керү номеры бирә.

Процедураның срогы: гариза кергәннән соң бер көн дәвамында.

3.4.2. Бүлек белгече тормышка ашыра:

- гариза бирүченең шәхесен билгеләү;

- гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә белән эш иткән очракта);

- әлеге Регламентның 2.5 пункты белән күздә тотылган документлар булуын тикшерү;

- тәкъдим ителгән документларның куелган таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен дөрем иттереп рәсмиләштерү, документларда чистартулар, өстәмә язулар, сызылган сүзләр һәм башка сөйләшенмәгән төзәтүләр булмавы);

Искәрмәләр булмаган очракта бүлек белгече тормышка ашыра:

- гаризаны кабул итү һәм аны теркәү;

- гариза бирүчегә тәкъдим ителгән документларның исемлеге күчермәләрен, документларны кабул итү датасы турында билге белән, вәкаләтле зат имзасы белән;

- гаризаны каралырга Башкарма комитет җитәкчесенә җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итүне алып баручы, гариза бирүчене гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр бирә һәм документларны исемлектә язмача аңлатып аңа документларны кире кайтара.

3.5. Ведомствора соратуларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, әгәр дә ул булмаган очракта  язмача формада әлеге регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән  мәгълүматларны һәм документалрны  алу өчен  соратулар җибәрә:

3.6. Документларны карау һәм анализлау.

3.6.1. Әлеге регламентның 2.5 һәм 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң, бүлек белгече:

- гариза белән тәкъдим ителгән һәм башкарма хакимият органнарында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә алынган документларны (мәгълүматларны) карау һәм анализлауны тормышка ашыра;

- гариза бирүче тарафыннан тәкъдим ителгән документларда дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар ачыкланган очракта, өстәмә документларны язмача формада соратуны тормышка ашыра, шулай ук әлеге документлар гариза бирүче тарафыннан тормышка ашырган исәпләүләрнең дөреслеге турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирмәгән очракта;

- тәкъдим ителгән өстәмә документларны карауны һәм анализлауны тормышка ашыра;

- РФ Хөкүмәтенең 480 номерлы карары нигезендә, күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсен билгеләүче критерийларга туры килү фактын билгели;

- бәяләмә проектын (бәяләмә бирү турында карар кабул ителгән очракта) яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат проектын (әгәр дә бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта) әзерли һәм рәсмиләштерә;

- имзалау өчен җибәрә:

1) Башкарма комитет җитәкчесенә – бәяләмә проектын (бәяләмә бирү турында карар кабул ителгән очракта);

2) Башкарма комитет җитәкчесенә – бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат проектын.

3.6.2. Башкарма комитет җитәкчесе бәяләмәне яки әлеге бәяләмәне бирүдән баш тарту турында, баш тартуның сәбәпләрен күрсәткән хатны имзалый. имзаланган документлар җаваплы хезмәткәргә теркәлү өчен җибәрелә.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү.

Башкарма комитет бүлеге белгече:

- бәяләмә бирү турында (бәяләмәне бирүдән баш тарту турында) карарны терки;

- гариза бирүчене (аның вәкилен), гаризада күрсәтелгән элемтә ысулы белән нәтиҗә турында, рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны тапшыру датасын һәм вакытын хәбәр итә;

- бирелгән бәяләмә бкенча мәгълүматны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка тапшыра:

- техник хатаны төзәтү турында әлеге Регламентка 5 нче кушымта нигезендәге формада гариза;

- техник хата булган документны;

- техник хата булуын раслаучы, юридик көчкә ия булган документлар.

Документта күрсәтелгән мәгълүматларда булган техник хаталарны төзәтү турында гариза гариза бирүче тарафыннан (вәкаләтле вәкил) шәхсән үзе, яисә почта аша бирелә.

3.8.2. Кергән хатларны теркәүче бүлек белгече, техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне тормышка ашыра, гаризаны беркетелгән документлары белән электрон документ әйләнеше системасында терки, шуннан соң аны каралу өчен Башкарма комитет җитәкчесенә җибәрә.

3.8.3. Бүлек белгече документларны карый һәм техник хатаны төзәтү турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет җитәкчесенең алдан бирелгән бәяләмәгә үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерли, килештерүгә һәм имзалауга җибәрә.

## IV. Дәүләт функциясен тормышка ашыру административ регламентын контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Административ регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт функцияләрен үтәүне башкаруга таләпләрне билгели торган хокукый актларны тотуны һәм башкаруны агымдагы контрольдә тоту, шулай ук карар карбул итү Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкечесе тарафыннан тормышка ашырыла.

4.1.1. Дәүләт функцияләрен башкару буенча агымдагы контрольне тормышка ашыру Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә торган эшләр һәм гамәлләрне планлы һәм планнан тыш тикшерү уздыру юлы белән уздырыла.

Планлы тикшерүләрне уздыру периодиклыгы һәм сроклары:

- ай саен – урынга чыгып һәм документар тикшерүләр уздырган вакытта;
- квартал саен – камераль тикшерүләр актларын сайлап тикшергән вакытта.

4.1.2. Дәүләт функциясен башкаруның тулылыгы һәм сыйфатын тикшерү барышында тикшерeләләр:

- урынга чыгып һәм документар тикшерүләр уздыру сыйфаты, тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе;
- төзүче һәм проект декларациясенең билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә (дәлилләнгән баш тарту) бирүгә нигезләр.

4.1.3. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатләрне карау планнан тыш уздырыла.

4.1.4. Контроль нәтиҗәләре буенча гаепле вазыйфаи затларны җаваплылыкка тарту гамәлдә булган Россия Федерациясе законнары нигезендә тормышка ашырыла.

## V. Дәүләт функцияләрен башкару буенча гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм аларның дәүләт функцияләрен тормышка ашырганда карарларына шикаять, кызыксынган зат тарафыннан язмача формада яки электрон документ формасында, шулай ук телдән формада (шәхси очрашу вакытында) тормышка ашырылырга мөмкин.

5.1.1. Шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) предметы булып дәүләт функциясен башкаруда катнашучы Башкарма комитет вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм дәүләт функциясен тормышка ашыру барышында кабул ителгән карарларга шикаять белдерү тора.

5.1.2. Шикаять язмача формада кәгазьдә яки электрон формада Биектау муниципаль районы башкарма комитетына бирелә.

5.1.3. Шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып – рәсми порталда, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.1.4. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) дәүләт функциясе башкару органы исеме, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче дәүләт функциясен башкаручы вазыйфаи затның, дәүләт хезмәткәренең, бүлек белгеченең, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), гариза бирүче – физик затның яшәү урыны турында белешмә яисә исеме, гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны турында белешмә, хәбәрләшү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) шикаять белдерелә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) вазыйфаи затның гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәүгә нигез булган дәлилләр.

5.1.5. Гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булган очракта), яисә аларның күчермәләре тәкъдим ителергә мөмкин.

5.1.6. Әгәр дә шикаять гариза бирүченең вәкиле аша бирелгән очракта, шулай ук гариза бирүче исеменнән гамәлләр кылуга вәкаләтләрне раслаучы документ тәкъдим ителә.

5.1.7. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына кертелгән шикаять, ул кертелгән көннән икенче көннән дә соңга калмыйча теркәлергә тиешле.

5.1.8. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына кергән шикаять, шикаятьләрне карау өчен вәкаләтле булган, түбәндәгеләрне тәэмин итүче вазыйфаи зат тарафыннан каралырга тиешле:

1) 59-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә шикаятьләрне кабул итү һәм карау;

2) гариза бирүчеләрне, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозучы карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат җиткерү.

5.1.9. Шикаять Биектау муниципаль районы Башкарма комитетында теркәлгәннән соң, 30 эш көне дәвамында каралырга тиешле.

5.1.10. Әгәр дә гариза бирүче тарафыннан Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына шикаятьне карау аның компетенциясенә кермәгән шикаять кертелсә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетында теркәлгәннән соң җиде эш көне дәвамында шикаять аны карау өчен вәкаләтле булган органга кире җибәрелә, бу турыда гариза бирүчегә язмача формада мәгълүмат җиткерелә. Шул ук вакытта шикаятьне карау срогы аны карау өчен вәкаләтле органда теркәлү көненнән санала.

5.1.11. Шикаятьне карауны туктатып тору күз алдында тотылмый.

5.1.12. Шикаятьне карау өчен вәкаләтле булган Биектау муниципль районы Башкарма комитеты вазыйфаи заты, шикаятьне дәлилләү һәм карау өчен кирәкле булган барлык мәгълүматны һәм документларны алырга хокуклы.

Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу, дәүләт функциясен башкару нәтиҗәсендә җибәрелгән хаталарны һәм хәреф хаталарын төзәтү формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.1.13. Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) язма рәвештә, гариза бирүченең (гариза бирүченең вәкиленең) теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.1.14. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү өчен, карар кабул ителгән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, тулы чаралар күрә.

5.1.15. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәге очракларда шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта:

1) шикаять турында шул ук предмет һәм шул ук нигезләр буенча үз көченә кергән суд, артбитраж суды карары;

2) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләре расланмаган зат тарафыннан шикаять бирелү;

3) Административ регламент таләпләре нигезендә моңа кадәр кабул ителгән, шул ук гариза бирүчегә карата һәм шул ук шикаять предметы буенча карар булу;

4) шикаятьне нигезсез дип тану;

5) Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты шикаятьне карау барышында һәм нәтиҗәләре буенча җинаять билгеләре булу. Әлеге очракта шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия булган вазыйфаи зат, булган материалларны кичектерүләрсез прокуратура органнарына җибәрә.

Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча җавапта күрсәтеләләр:

а) шикаять буенча карар кабул иткән Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта);

б) гариза бирүче – юридик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) яки исеме;

в) шикаять буенча карар кабул итү өчен нигезләр;

г) шикаять буенча кабул ителгән карар;

д) әгәр дә шикаять нигезле дип табылган очракта, - ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү сроклары;

е) әгәр дә шикаять нигезсез дип табылган очракта, - шикаятьне нигезсез дип тану сәбәпләре һәм гариза бирүченең суд тәртибендә кабул ителгән карарга шикаять белдерү хокукы турында мәгълүмат;

ж) шикаять буенча кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүматлар.

5.1.16. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча җавап шикаятьне карау өчен вәкаләтле Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи заты тарафыннан имзалана. Гариза бирүченең теләге буенча шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча җавап, карар кабул ителгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, электрон документ формасында, шикаятьне карарга вәкаләтле вазыйфаи зат һәм (яки) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән шикаятьне карауга вәкаләтле орган төре тарафыннан электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында тәкъдим ителергә мөмкин.

5.1.17. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәге очракларда шикаятьне җавапсыз калдырырга мөмкин:

1) шикаятьтә гариза бирүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон почта адресы) булмау;

2) шикаятьтә цензурага туры килмәгән яки хурлау сүзләре, вазыйфаи затның һәм аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм милкенә янау булу (шикаять җавапсыз кала, шул ук вакытта гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) хокуклар белән дөрес итеп кулланмауның рөхсәт ителмәве турында хәбәр ителә);

3) шикаять текстының нинди дә булса бер өлешен уку мөмкинлеге булмавы (шикаять җавапсыз кала, бу хакта шикаять теркәлгән көннән соң җиде көн дәвамында гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) хәбәр ителә, әгәр дә аның фамилиясе һәм почта адресын укрыга мөмкин булса).

5.1.18. Гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) шикаять буенча суд тәртибендә кабул ителгән карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.


5.1.19. Дәүләт функциясен башкару буенча карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга)  судка кадәр шикаять белдерү нәтиҗәләрен теркәү ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында  тормышка ашырыла.

5.1.20. Дәүләт функциясен башкару буенча карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга)  судка кадәр шикаять белдерү нәтиҗәләре булып, шикаятьне канәгатьләндерү яисә шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында җавап булган карар тора.

1 нче кушымта

Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруны (форма) билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү буенча Административ регламентка

Дәүләт функциясен башкару блок-схемасы



2 нче кушымта

Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруны (форма) билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү буенча Административ регламентка

______________________________________

(өлешле төзелеш өлкәсендә контроль (күзәтчелекне) тормышка ашыра торган Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы исеме)

______________________________________

(юридик зат – төзүченең исеме, юридик адресы, почта адресы, телефоны)

Төзелеш проекты әзерлеге турында
ГАРИЗА

Әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирүегезне сорыйм ____________________________________________________________________________________

_______(төзелешкә рөхсәт нигезендә төзелеш проекты исеме)

| | |
|---|---|
| **1.Төзүче турында мәгълүмат** | |
| 1.1. Төзүченең исеме, оештыру хокук формасын күрсәтеп | |
| 1.2. Төзүченең ОГРНы | |
| 1.3. Төзүченең ИННы | |
| **2. Төзүченең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе һәм төзелгән өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре санын ачыклаучы, 2019 елның 1 нче июленнән соң дәүләт теркәвенә тәкъдим ителгән өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча, “Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә катнашу һәм Россия** | |

| | |
|---|---|
| **Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законның 15$^4$ стататьясы белән каралган счетларны кулланмыйча, әлеге шартларга туры килгән очракта төзүчегә өлешле төзелеш катнашучыларның акчаларын җәлеп итү хокукы бирелү критерийларына туры килүне ачыклаучы карарының 3 пункты, “в” пунктчасы, икенче абзацы белән күз алдында тотылган критерияләргә туры килүе турында мәгълүмат.** | |
| 2.1. Ведомствоара комиссия тарафыннан карар кабул итү датасы | |
| 2.2. Ведомствоара комиссия утырышының беркетмәсе номеры | |
| **3. Төзелеш проекты турында мәгълүмат** | |
| 3.1. Гамәлдә булган төзелешкә рөхсәт нигезендә төзелеш проекты исеме | |
| 3.2. Төзелеш тормышка ашырылучы территория урнашкан Россия Федерациясе субъекты | |
| 3.3. Төзелеш алып барыла торган территория урнашкан торак пункт исеме | |
| 3.4. Төзелешкә рөхсәт бирү номеры | |
| 3.5. Төзелешкә рөхсәт бирүне бирү датасы | |
| 3.6. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы | |
| 3.7. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булуын озайтуның ахыргы датасы | |
| 3.8. Төзелешкә рөхсәт биргән органның исеме | |
| 3.9. Төзелешкә гамәлдә булган рөхсәт нигезендә, төзелеш проекты составында капиталь төзекләндерү объектларының гомуми мәйданы | |
| 3.10. Төзелешкә гамәлдә булган рөхсәт нигезендә, төзелеш проекты составында мөстәкыйль капиталь төзекләндерү объектларының саны | |
| **4. Төзелеш этаплары турында мәгълүмат** | |
| 4.1. 1 нче этап | |
| 4.1.1. Этап белән төзелешләре күз аалдында тотылган капиталь төзекләндерү объектларының гомуми мәйданы | |
| 4.2. 2 нче этап | |
| * | |

| | |
|---|---|
| **5. Төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән барлык капиталь төзелеш объектларының конструктив элементларының әзерлеге нигезендә барсын кушып саналган төзелеш проектының/төзелеш этапларының әзерлек дәрәҗәсе, %** | |
| **6. Төзелешкә фактта тотылган чыгымнар күләменнән чыгып саналган төзелеш проектының/төзелеш этапларының әзерлек дәрәҗәсе, %** | |
| **7. Төзелеш проектының/төзелеш проекты этапларының әзерлек дәрәҗәсе критерияләрен куллану нигезләре, “Күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе һәм төзелгән өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре санын ачыклаучы, 2019 елның 1 нче июленнән соң дәүләт теркәвенә тәкъдим ителгән өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча, “Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законның 15[4] стататьясы белән каралган счетларны кулланмыйча, әлеге шартларга туры килгән очракта төзүчегә өлешле төзелеш катнашучыларның акчаларын җәлеп итү хокукы бирелү критерийларына туры килүне ачыклаучы карарының 3 пунктының “б” пунктчасы, “в” пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацлары белән күз алдында тотылган критерийлар** | |
| 7.1. Төзелгән территорияне үстерү, территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә, шул исәптән стандарт торак төзү, хокукларга ия булучылар инициативасы белән территорияне комплекслы үстерү, җирле үзидарә органнары инициативасы белән территорияне комплекслы үстерү максатларында | |
| 7.1.1. Шартнамә (килешү) төре | |
| 7.1.2. Шартнамә (килешү) номеры | |
| 7.1.3. Шартнамәне (килешүне) төзү датасы | |
| 7.2. Төзүченең дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы белән төзегән шартнамәләре һәм килешүләре (шул исәптән инвестицион), әгәр дә | |

| | |
|---|---|
| әлеге шартнамәләр яки килешүләр белән төзүченең социаль объектларны һәм (яки) инженер-техник инфраструктураны дәүләт яки муниципаль милеккә тапшыру һәм (яки) тузган һәм авария хәлендәге торакны бетерү каралган булса; | |
| 7.2.1. Шартнамә (килешү) төре | |
| 7.2.2. Шартнамә (килешү) номеры | |
| 7.2.3. Шартнамәне (килешүне) төзү датасы | |
| 7.3. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыру буенча, алар белән әлеге территория чикләрендә инженер-техник инфраструктура, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләре, шифаханәләр урнаштыру өчен билгеләнгән социаль инфраструктура объектлары төзелешен алып бару һәм (яки) төзекләндерү уздыру күз алдында тотылган документация | |
| 7.3.1. Документның төре | |
| 7.3.2. Документның номеры | |
| 7.3.3. Документның датасы | |
| 7.4. Тәмамланмаган төзелеш объектының төзелешен тәмамлау турында килешү һәм төзүченең күпфатирлы йортлар төзү өчен акчалары җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган, “Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль закон нигезендә зыян күргән гражданнар реестрына кертелгән гражданнар алдында йөкләмәләрен үтәве, яисә төзүченең әлеге проектка хокукы “Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында” Федераль законның $201^{15\text{-}1}$ һәм $201^{15\text{-}2}$ статьялары белән күздә тотылган тәртиптә алынган булган нигездә | |
| 7.4.1. Шартнамә (килешү) төре | |
| 7.4.2. Шартнамә (килешү) номеры | |
| 7.4.3. Шартнамәне (килешүне) төзү датасы | |
| 7.5. Төзелеш проекты тормышка ашырыла торган җир кишәрлегенә хокуклар төзүче тарафыннан Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{6}$ статьясы 2 пункты 3 һәм $3^{1}$ пунктчалары белән билгеләнгән нигездә алынган | |
| 7.5.1. Шартнамә (килешү), хакимият органының боеру акты төре | |

| | |
|---|---|
| 7.5.2. Шартнамә (килешү), хакимият органының боеру акты номеры | |
| 7.5.3. Шартнамә (килешү) төзү, хакимият органының боеру актын чыгару датасы | |
| **8. Төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән барлык капиталь төзелеш объектларының конструктив элементларының әзерлеге нигезендә барысын кушып саналган төзелеш проектының/төзелеш этапларының әзерлек дәрәҗәсенраслау расланган/ расланмаган** | |
| 8.1. Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашыруга вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы/ кадастр инженерларының үзкөйләнә торган оешмасы исеме | |
| 8.2. Төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән барлык капиталь төзелеш объектларының конструктив элементларының әзерлеге нигезендә барсын кушып саналган төзелеш проектының/төзелеш этапларының әзерлек дәрәҗәсен раслаучы затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | |
| **9. Проект декларациясе нигезендә төзелештә өлешле төзелеш шартнамәләре төзелергә мөмкин булган төзелеш проекты/төзелеш этаплары торак һәм торак булмаган биналарның, машина урыннарының гомуми мәйданы, м$^2$** | |
| 9.1. Торак биналарның гомуми мәйданы, м$^2$ | |
| 9.2. Торак булмаган биналарның гомуми мәйданы, м$^2$ | |
| 9.3. Машина урыннарының гомуми мәйданы, м$^2$ | |
| **10. Өлешле төзелеш катнашучыларының торак һәм торак булмаган биналар, машина урыннарының гомуми мәйданы 10% да ким булмавын раслаучы, төзелгән өлешле төзелештә катнашу шартнамәләренең саны, штук/ м$^2$** | |
| 10.1. Торак биналарга карата өлешле төзелештә катнашуның төзелгән шартнамәләре саны, штук/м$^2$ | |
| 10.2. Торак булмаган биналарга карата өлешле төзелештә катнашуның төзелгән шартнамәләре саны, штук/м$^2$ | |
| 10.3. Машина урыннарына карата өлешле төзелештә катнашуның төзелгән шартнамәләре саны, штук/м$^2$ | |
| **11. Гаризага кушымта _____ биттә** | |

________________________________________
__________________________________________________

(оешма җитәкчесе) (имза) (фамилия, исем, әтисенең исеме (ахыргысы – булган очракта)

________________________________________
__________________________________________________

(оешманың баш бухгалтеры) (имза) (фамилия, исем, әтисенең исеме (ахыргысы – булган очракта)

М.У. (мөһер булган очракта)
"__" ____________ 20__ ел

3 нче кушымта

Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруны (форма) билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү буенча Административ регламентка

**Төзүче тарафыннан тәкъдим ителә торган күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының, әлеге объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре санын ачыклаучы, 2019 елның 1 нче июленнән соң дәүләт теркәвенә тәкъдим ителгән өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча, 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 стататьясы белән каралган счетларны кулланмыйча, әлеге шартларга туры килгән очракта төзүчегә өлешле төзелеш катнашучыларның акчаларын җәлеп итү хокукы бирелү критерийларына туры килүне ачыклаучы документлар исемлеге**

Документлар пакеты Башкарма комитетка тәкъдим ителә (Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Кооперативная урамы, 5 нче йорт, 113 кабинет).

1. Төзелеш проекты әзерлеге турында гариза һәрбер объектка форма буенча 2 нөсхәдә;

2. Вәкилгә ышанычнамә, вәкиллекле затның хәбәрләшү өчен белешмәләре (документлар төзүченең директоры/җитәкечесе булмаган зат тарафыннан бирелгән очракта);

3. Төзелеш өчен фактта тотылган чыгымнар күләменнән чыгып саналган әзерлек дәрәҗәсен исәпләү, (форма буенча), төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга һәм төзелеш объекты буенча челтәрләргә шартнамәләрне кертеп;

4. Төзелеш өчен рөхсәттә күрсәтелгән барлык күчемсез милек объектларының конструктив элементларының әзерлеге нигезендә суммар саналган проектның

әзерлек дәрәҗәсен, махсуслаштырылган оешма тарафыннан башкарылган санау (кадастр инженеры санавы);

5. Өлешле төзелештә катнашу шартнамәләрендә теркәлү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

6. Төзелеш проекты әзерлеге турында гариза биргәнгә кадәр 15 көннән дә иртә булмаган вакытта формалаштырылган төзүченең квартал саен хисабы;

7. Төзүченең бухгалтер хисабы регистры яки төзелеш проектына карата алардан өземтә.

4 нче кушымта

Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруны (форма) билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү буенча Административ регламентка

________________ № ______________ ________________________

№___ __________ ______________ ________________________

**Объектның әзерлек дәрәҗәсе һәм "Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясы белән күздә тотылган счетларны кулланмыйча өлешле төзелештә катнашу шартнамәләрен төзү мөмкинлеге турында бәяләмә**

Төзүченең исеме: _____________________________________________

Төзүченең ОГРНы: ______________________________________________

Төзүченең ИННы : ______________________________________________

Төзелеш проекты исеме: ___________________________________

Капиталь төзелеш объекты адресы:________________________________

Төзелешкә рөхсәт ___________________________________________

ЕИСЖСта проект декларациясенең номеры______________________________

Җир кишәрлегенең кадастр номеры__________________________________

Әлеге бәяләмә ___________________________ объектның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йортның һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсен ачыклаучы критерийлар һәм өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең саны турында, туры килгән очракта төзүчегә өлешле төзелеш катнашучыларының акчаларын җәлеп итү хокукы тәкъдим итеlә, "Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу

турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законның 15 статьясы белән күз алдында тотылган счетларны кулланмыйча, 2019 ел, 22 нче апрель, (алга таба – РФ Карары критерийлары, №480), карарын туры килүен раслый, атап әйткәндә:

| № т/б | Критерийларның исеме | Туры килү турында тамга |
|---|---|---|
| 1 | 480 номерлы Карарның 2 пункты нигезендә төзелгән катнашу шартнамәләре саны | |
| 2 | 480 номерлы Карар критерияләренә объектның әзерлек дәрәҗәсе | |

5 нче кушымта

Россия Федерациясе Хөкүмәте куйган критерийларга туры килгән, объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең санын билгеләүче һәм билгеле мәгълүматларны торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруны (форма) билгеләүче, төзүчегә күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектының әзерлек дәрәҗәсе турында бәяләмә бирү буенча Административ регламентка

Кемгә: ______________________

Кемнән: ________________________

**Техник хатаны төзәтү турында**

**гариза**

Дәүләт хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ____________________________________________________________________

(хезмәтнең исеме)

Язылган:______________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_________________________________________

______________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.______________________________________________________________

2.______________________________________________________________

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта әлеге карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны E-mail адресына җибәрү юлы белән:____________________;

почта аша кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә, түбәндәге адрес буенча: ___________________________________________.

Шәхсән мәгълүматларны эшкәртүгә (муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында

шәхси мәгълүматларны җыю, системага салу, туплау, саклау, аныклау (үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), зарарсызландыру, блоклау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, раслыйм.

Минем шәхесемә кагылышлы, шулай ук минем турыда кертелгән мәгълүматлар дөрес дип саныйм. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар күрсәтелгән.

_______________      ___________________ ( ___________________)

(дата)      (имза)      (фамилия, исем, әтисенең исеме)